ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.06.2017 Казан ш. № 4-1/г

Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Федераль тарифлар хезмәтенең «Халыкка сатыла торган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2011 елның 27 октябрендәге 252-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга 2017 елның 1 июленнән башлап 5,48 сум/куб. м. (НДС исәпкә алып) күләмендә ваклап сату бәясен билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында» 10.06.2016 № 4-1/г карарының 1 пунктының 2017 елның 1 июленнән көчен югалтуын танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов